КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 25 март г.Казань № 271

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Наше время – Безнең заман» Татарстан Республикасының эшләүче яшьләре иҗатының еллык ачык республика телевизион фестивален үткәрү турында» 2016 ел, 9 июнь, 386 нчы карары белән расланган «Наше время – Безнең заман» Татарстан Республикасының эшләүче яшьләре иҗатының еллык ачык республика телевизион фестивален әзерләү һәм үткәрү буенча оештыру комитеты составына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Наше время – Безнең заман» Татарстан Республикасының эшләүче яшьләре иҗатының еллык ачык республика телевизион фестивален үткәрү турында» 2016 ел, 9 июнь, 386 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 14 июнь, 485 нче; 2018 ел, 24 август, 697 нче; 2019 ел, 19 апрель, 309 нчы; 2019 ел, 15 май, 394 нче; 2019 ел, 20 декабрь, 1177 нче; 2020 ел, 6 март, 179 нчы; 2020 ел, 21 сентябрь, 849 нчы; 2021 ел, 13 апрель, 244 нче һәм 2021 ел, 6 октябрь, 956 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Наше время – Безнең заман» Татарстан Республикасының эшләүче яшьләре иҗатының еллык ачык республика телевизион фестивален әзерләү һәм үткәрү буенча оештыру комитеты составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

оештыру комитеты составына түбәндәгеләрне кертергә:

Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башлыгы Илсур Рәис улы Метшинны (килешү буенча);

Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министры Айрат Ринат улы Хәйруллинны.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин